КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 3 ноябрь г.Казань № 1045

Татарстан Республикасы Министрлар
Кабинетының кайбер карарларына
үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2021 елга Татарстан Республикасы социаль хезмәт күрсәтү оешмаларының норматив чыгымнарын раслау турында» 2020 ел, 30 сентябрь, 887 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 19 декабрь, 1159 нчы; 2021 ел, 27 гыйнвар, 28 нче; 2021 ел, 25 февраль, 95 нче; 2021 ел, 26 май, 375 нче; 2021 ел, 28 июль, 662 нче; 2021 ел, 13 сентябрь, 867 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган 2021 елга социаль-көнкүреш хезмәтләре, социаль-медицина хезмәтләре, социаль-психологик хезмәтләр, социаль-педагогик хезмәтләр, социаль-хезмәт хезмәтләре, социаль-хокукый хезмәтләр, социаль хезмәтләрдән файдаланучыларның коммуникатив потенциалын арттыру максатларындагы хезмәтләр күрсәтүне кертеп, стационар формада социаль хезмәт күрсәтү буенча дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә норматив чыгымнарда:

I бүлекнең 2 пунктындагы 2 графасында «Психоневрологик интернатлар» сүзләрен «Психик бозылышлары булган гражданнар өчен интернат йортлар» сүзләренә алмаштырырга;

II бүлекнең 2 пунктындагы 2 графасында «Психоневрологик интернатлар» сүзләрен «Психик бозылышлары булган гражданнар өчен интернат йортлар» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган 2021 елга дәүләт хезмәтен күрсәтүгә бәйле гомумхуҗалык ихтыяҗлары өчен норматив чыгымнарга карата төзәтү коэффициентларының 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «2. | Психик бозылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән интернат йортлар | |
| 2.1. | «Психик бозылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән Алабуга интернат йорты» ДАСХКУ | 0,94 |
| 2.2. | «Психик бозылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән Зеленодольск интернат йорты» ДАСХКУ | 0,97 |
| 2.3. | «Психик бозылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән Чистай интернат йорты» ДАСХКУ | 1,12 |
| 2.4. | «Психик бозылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән Казан интернат йорты» ДАСХКУ | 1,32 |
| 2.5. | «Психик бозылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән Яңа Чүриле интернат йорты» ДАСХКУ | 1,45 |
| 2.6. | «Психик бозылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән Кама Аланы интернат йорты» ДАСХКУ | 1,05»; |

әлеге карар белән расланган 2021 елга стационар социаль хезмәт күрсәтү формасы булган дәүләт оешмаларында койка көннәре һәм койка урыннары санында:

«Арча муниципаль районы» юлының 2 графасында «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Яңа Чүриле психоневрологик интернат» ДАСХКУ» сүзләрен «Психик бозылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән Яңа Чүриле интернат йорты» ДАСХКУ» сүзләренә алмаштырырга;

«Алабуга муниципаль районы» юлының 2 графасында «Алабуга психоневрологик интернаты» ДАСХКУ» сүзләрен «Психик бозылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән Алабуга интернат йорты» ДАСХКУ» сүзләренә алмаштырырга;

«Түбән Кама муниципаль районы» юлының 2 графасында «Заманча медик-социаль тернәкләндерү технологияләре кулланыла торган Кама Аланы психоневрологик интернаты» ДАСХКУ» сүзләрен «Психик бозылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән Кама Аланы интернат йорты» ДАСХКУ» сүзләренә алмаштырырга;

«Чистай муниципаль районы» юлының 2 графасында «Чистай психоневрологик интернат» ДАСХКУ» сүзләрен «Психик бозылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән Чистай интернат йорты» ДАСХКУ» сүзләренә алмаштырырга;

«Казан шәһәре» юлының 2 графасында «Казан психоневрологик интернаты» ДАСХКУ» сүзләрен «Психик бозылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән Казан интернат йорты» ДАСХКУ» сүзләренә алмаштырырга.

2. «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2021 елга Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтү оешмаларының норматив чыгымнарын раслау турында» 2020 ел, 30 сентябрь, 887 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2021 ел, 13 сентябрь, 867 нче Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына, 2 пунктта «ундүртенче» сүзен «икенче» сүзенә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

3. Бу карарның 1 нче пункты гамәле 2021 елның 31 маеннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин